# CONVERSION IN THE PARTS OF SPEECH OF THE TATAR LANGUAGE AND CERTAIN ISSUES OF SPELLING

**Ruzal Abdullazyanovich Yusupov,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russia,
dilara-47@mail.ru.

The paper considers the features of a conversion mechanizm in the Tatar language. The author seeks to refute the point of view entrenched in the modern. Tatar linguistics, according to which any contextual meaning of the word is considered to be a ground for defining this phenomenon as transition of the word from one part of speech to another. Based on the analysis of linguistic material, a conclusion is made that the polysemy of lexical units should be taken into account when considering the cases of conversion. As for the spelling of certain words, the author expresses his concern about the unwarranted enthusiasm for fused spelling resently observed in language practice, although separate components of these words fully retain their independent meanings.

**Key words**: transition of words from one part of speech to another, conversion, word formation, affixes, joined-up or separate spelling of words, compound words and phrases.

In spite of the fact that the study of parts of speech of the Tatar language has been going on for more than a century and a half, there is no unified opinion in all issues of this area. Naturally, scientific views cannot be identical and nothing of material and spiritual life can exist without change. We also observe the same in linguistics: thoughts and opinions differ about the explanation of some peculiarities of history of the language, its present state and the peculiar properties of changing words. It is undeniable.

However, the task of linguists is an objective reflection of linguistic phenomena, achieving a unity of opinions on major issues, when studying different aspects of the language.

The purpose of this article is the coverage of such issues as grouping Tatar words into parts of speech and the transition of words from one part of speech to another – conversion and joined-up or the separate spelling of words.

In the course of time the number of scholars and their researches grows and linguistics branches as a science. It becomes difficult to explain all the language features and nuances, and the tendency to put lively and constantly altering language into frames of rules becomes much stronger.

The transition of words from one part of speech to another, proposals to do joined-up writing of some separate words and also other different views about aspects of the Tatar linguistics can be proven by many opinions in different researches.

During the last two or three decades in the study of word formation of Tatar linguistics the theory of transition of words from one part of speech to another has become wide spread. In the scientific work “Tatar Grammar” which was published in 1993 and in several other works, are described the transition of hundreds of nouns from the part of nouns to the part of adjectives, the transition of adjectives to the part of nouns and other transitions [1]. For example, according to this work, the words *chal, saŋgyrau, izge, keche, kyzu, yaŋa, iske, käkre, kötächäk* are transited to the part of nouns, and the words *yefäk, sitsy, altyn, kömesh, pyyala, agach, salam, yon, kübäläk, garmun, dus, aryslan, dala, tau* are transited to the part of adjectives [1: 334-339, 393-404].

Generally, scholars should be more cautious when dealing with the notion of conversion, because absolutisation of this phenomenon is not always justified. But in spite of it many researchers are devoted to this topic. The main reason for this is the attempts in grammar books to categorically adjust every word or word combination with a definite rule or scheme.

For example, let us look at the word combinations *kömesh alka, bakyr savyt, agach shkaf* where the first word means the material and the second word means the object itself. The first word of these combinations and many other words meaning the material of making things in the work “Word formation in the modern Tatar literary language” are explained as words which are transited from the part of nouns to the part of adjectives by conversion [2: 201-202].

The author probably named the words *kömesh, bakyr, agach* as adjectives following the fact that the Russian language has a category of “relative adjectives” (for comparison: *kömesh* alka – *serebryanyye ser’gi* (*silver* earrings), *bakyr* savyt –

*mednaya* posuda (*copper* utensils), *agach* shkaf – *derevyannyy* shkaf (a *wooden* wardrobe).

Another reason for explaining the words meaning the material of making things as adjectives which can be seen through the above examples is possibly a one-sided view on the definition of an adjective as a part of speech in grammar books. It states that "An adjective is a part of speech which answers the questions *nindi? (what kind of?) kaidagy? kaisy? (which?)* and determines the features of an object". However, this definition would be more accurate if it had the following additional word «constant» before the word "feature", and in this case the point of an adjective would be better expressed.

Moreover, it has become habitual to name all words which answer the question *nindi? (what kind of?*) as adjectives. It does not fully reflect reality: we cannot say that all words answering the question *nindi? (what kind of?*) in all cases determine the features of an object. M.Z.Zakiyev, D.G.Tumasheva, F.M.Khisamova and other well-known linguists trying to prove their opinions very convincingly say that identifying parts of speech, different features of words and the roles of words in speech should be studied [3: 13-15; 4: 22-31, 41-42; 5: 59-64]. The most used and prevalent lexical meanings of words and their basic syntactic functions play an important decisive role when determining the parts of speech.

Despite the fact that in the word combinations *yefäk külmäk, altyn sägat', timer köräk* the words *yefäk, altyn, timer* answer the question *nindi? (what kind of?*) they do not denote the features of these words, but denote the material they are made of. And the material is also a subject. If this kind of word combination was denoted as a compound noun where one noun is a subject itself and the other is a material the subject is made of, then possibly it would be more correct. For example: *yefäk külmäk (a silk dress)* – is one whole notion, *altyn sägat' (a gold watch)* is one whole notion and *timer köräk (a steel spade)* is also one whole notion. And these compound nouns can be added to by some adjectives which denote the features of the mentioned subjects: *näfis yefäk külmäk (an elegant silk dress), matur altyn sägat' (a nice gold watch)* and *uŋayly timer köräk (a handy steel spade)*.

The Tatar language has thousands of such word combinations which are in fact peculiar compound nouns: *timer yul (a railroad), asphal't yul (an asphalt road), agach yort (a wood house), kün kurtka (a leather jacket), yon kofta (a wool cardigan)*. It should also be noted that in spite of the fact that the second component of the word combinations, such as *tashayak (tash savyt), ir keshe, ir bala, kyz bala, student yeget, vrach kyz,* (that we have long been accustomed to call "compound nouns" or "complex nouns") could formally answer the question *nindi?* concerning the first component, we cannot call the words *tash, ir, kyz, student, vrach* as the words signifying features of the words *ayak (savyt), keshe, bala, yeget, kyz*. Each of these combinations as whole compound nouns can be supplemented by words signifying features – adjectives: *matur tashayak (tash savyt), tyrysh ir keshe, akylly ir bala, chibär kyz bala, uŋgan student yeget, igelekle vrach kyz*, *iske timer shkaf.*

The first volume of "Tatar Language Grammar" has many examples of the phenomenon of the conversion of numerous adjectives to the group of nouns. Let us look at some of them and think them over [1: 334-339].

It is impossible to accept the consideration of the words *ak, kyyu, sylu, izge, ölkän, karaŋgy, kyzu, yaŋa, vatyk* as nouns, as words converting from the group of adjectives to the group of nouns and as words denoting subjects. For example, when we say *ak (white)* or *yaŋa (new)* primarily we imagine a white or a new thing. If we make up the sentence *Ak kilä (White is coming)*, we cannot consider the word *ak* as a noun, because there is no meaning of the subject in it. And in the sentence *Keshe (ir keshe) kilä* (the man is coming) the lexical meaning of the word *keshe* is clear: it denotes the subject and applies to the group of nouns.

It is obvious that the basis of the transition of words from one part of speech to another i.e. the basis of word formation by conversion is in the following: sometimes during speech the main word of the combination falls out and the word subordinated to this word accepts its grammar affixes and lexical meaning whilst maintaining the context: *ukuchy kyznyŋ kitaby – ukuchynyŋ kitaby; gönahsyz balalarnyŋ küz yäshe – gönahsyzlarnyŋ küz yäshe; min küp närsälär kürdem – min küpne kürdem; ikenche kitap onytylyp kalgan – ikenchese onytylyp kalgan,* etc.

Words represented by some linguists as transiting from one part of speech to another differ in the degree of conservation or the loss of their first meaning and the degree of activeness of using the new meaning. It would be more correct to denote them as words with contextual meaning, which are seldom used and only in specific cases. For example, *"Ukuchylar kichä ütkän materialny kabatladylar" – "Ukuchylar kichä ütkänne kabatladylar".*

Comparing sentences we see the following: because of the falling of the word *material* out of the word combination *ütkän material*, the subordinate word *ütkän* accepted grammar affixes and the meaning of the subject of the word *material*. But there cannot be a serious base to consider that the word *ütkän* acquired a new meaning through conversion.

Total conversion, or the total transition of the word from one part of speech to another, means the total loss of the former lexical-grammatical meaning and starting to use a new lexical-grammatical meaning. For instance, the words *yäshlär, kyzyllar, aklar, kürshe, ukytuchy, ukuchy, tegüche, yazuchy, buyau, yazu, belderü, saylau* totally transited from the group of participles and the group of action nouns to the group of nouns.

But even the words subject to total conversion do not lose the previous meanings. For example: *Bezgä yazuchylar* (noun) *kilde. Prezidiumda berketmä yazuchy* (participle) *keshe utyra ide.* (*Kürshem* (noun) – *bik äybät keshe*. *Kürshe* (adjective) *avyldan kunaklar kilde*. *Khalkybyz zur žiŋügä* (noun) *ireshte. Yaryshta žiŋü* (action noun) – *härkemneŋ teläge.*

Generally, the transition of some words from one part of speech to another without any formal changes can be considered as a new method of word formation but only conditionally. It would be wrong to designate these kinds of words as newly formed words with a new meaning, because in word formation the change should be both in the meaning and in the form. In our opinion, word formation means forming new words morphologically (by affixation – *igen+che, yagu+lyk, äŋgämä+däsh, karshy+la, tyrma+la*) and phonetically *(sypyru – seberü, kür – küz, bagyr – bägyr')*.

In the field of word formation there is an issue which has not yet been determined: it is the discussion whether the affixes *-ly/-le, -syz/-sez, -dagy/ -däge (-tagy/-täge)* are joined to nouns and form adjectives or if they just connect nouns. In traditional grammar books these kinds of affixes are considered to be word-formative affixes. At the same time M.Z.Zakiyev, D.G.Tumasheva, F.M.Khisamova and some other linguists say that these affixes basically perform grammatical functions [3: 13-15; 4: 92-97; 5: 122-124].

For example, it is evident that words formed by means of these affixes and which are substantially noted as adjectives are not adjectives. The main objective of the affixes *-ly/-le* is the expression of the relationship of the object in the root of the word to someone or something: *atly* (he has a horse) *krestyan, balaly* (she has a baby) *khatyn, pärdäle* (it has a curtain) *täräzä*. However, in some cases these affixes do not only show the presence of an object in another, but add some nuance of positive evaluation: *echtälekle* (with a rich content) *äsär, bashly* (clever, brainy) *keshe*.

The main objective of the affixes *-syz/-sez* is the expression of the absence of an object mentioned in the root of the word in another object by attaching the affixes: *bakchasyz* (it has no orchard) *yort, koyashsyz* (without the sun) *kön*. But sometimes these affixes define features of an object: *densez* (blasphemous), *imansyz* (bad) *keshe*.

The main role of the affixes *-dagy/-däge (-tagy/-täge)*, consisting of two parts is the expression of the place of one object to another: *urmandagy agachlar (the trees in the forest), kyrdagy igennär (grains in the field).*

The definition of the affixes *-ly/-le* as the affixes of the case of presence and the affixes *-syz/ -sez* as the affixes of absence would have been closer to the truth.

The affixes *-gy/-ge//-ky/-ke,* which are considered to be the affixes forming relative adjectives, are not in fact formed from a noun – adjectives expressing features of an object. In the word combination *Kyshky yul* the word "*kyshky*" does not define the feature of the object expressed in this combination by the word *yul* but it expresses its relationship to time: *kyshky* (being in winter) *yul, žäyge* (being in summer) *kön, kichke* (being eaten in the evening) *ash, asky* (lower) *kat*. If these affixes form a word with a new meaning (in the language there are many polyfunctional affixes) they can be considered as word-formative affixes.

In seriously approaching this problem, we suppose that a transition of words from one part of speech to another and similar concepts do not correspond to logic. When grouping the words we seem to forget that they are basically polysemantic. If we worked whilst remembering this very important phenomenon – the polysemy of words – and if we grouped the words (the parts of speech) without the notion "transition from one part to another" but according to their meaning and grammatical indicators, then this would be more correct. Acting in this way, for example, we would say that the word *salkyn* defines a sign of air (*salkyn hava*) and refers to the group of adjectives, but in the word combination *yanvar' salkynnary* it is a noun. And there would not be any dispute about the belonging of words to any parts of speech. For instance, *ishektän salkyn* (noun) *kerä. Salkyn* (adjective) *kysh bashlandy*.

Words are lexical units which are lexically and grammatically not separated (not differentiated) from each other. This phenomenon is connected to the nature of the origin of language: it is assumed that first of all people thought up a name for an object and then also described the features of the object by this noun. That is why it seems to be unnecessary to try to discover the nuances of transition of this kind of word to another part and it also seems to be impossible. Each of them is used in their contextual meaning in every specific case or more accurately native speakers use them on their request. Therefore, according to the information in the work "Word formation in the modern literary Tatar language" [2: 228], the words *döres, azat, akryn, anyk, alama, ozyn, nachar, kire, yakhshy, taza, tirän, avyr, žiŋel, yyrak* should not be designated as "adjectives transiting only to the group of adverbs". Language is a live and remarkably complicated phenomenon, its words are peculiar, polisemantic and ornate and they are quite unyielding: they cannot be forced into a frame of rules. For example, among the adjectives having been denoted as transiting only to the group of adverbs there is the word *avyr* which is also used as a noun in the meanings of *yök, korsak, kömän* (*Avyry bar, küräseŋ*).

We should probably not include overly complicated, controversial information in normative language textbooks or teaching aids. Grammar, grammatic rules and other theoretical material should be a good basis for practical language learning and for teaching pupils to speak their native language correctly and well. In educational establishments in recent years language learning has been taught more as theoretical material, rather than as a mean of live communication.

Developing the idea of the practical importance of linguistics, we would like to express our opinion about one more significant issue. It is the problem of the joined-up or separate spelling of some words. The point is in the following: the joined-up or separate spelling of words in the press, in different books and, in general, in our written language is not yet fully defined, that is why there are a lot of words written differently.

Nowadays, in the field of spelling word confusion and different views occupy a large place. It is one of the most serious problems. Linguists should come to a common view, solve this problem in the near future and write new orthographic textbooks.

The main problem concerning the correct spelling of words is the unreasonable joined-up writing of compounds which should be written separately. Recently, works on writing compounds and word combinations have not been followed by concrete rules.

Nowadays, the tendency for the joined-up spelling of the parts of compound words which have their own independent meanings has become a habit. For example, in the above-mentioned work "Word formation in the modern literary Tatar language" many words which were previously written separately are now joined. Even the title of the book has this kind of word – *süzyasalysy* and the reason for this spelling is not explained. Though *süz yasalyshy* is not a compound, but a word combination! According to this book, such compound words as *küpmillätle, küpbalaly, küpbuynly, küpsüzle, sarychächle, ozynkully, öchfazaly, beryakly, ikeyakly, taŋkaldyrgych, echposhyrgych, bishyyllyk, unkönlek, bishkönlek, öchatnalyk* [2: 199], having independent meaningful components, should not be put together: they should be written separately. And the words *paryasaly, žirteträü, bashäylänü, bermägnäle, berkatly, bermögezle, karakük, karakyzyl, karayäshel, kükselkara, chiyäkyzyl, shomyrtkara, äflisunsary*, *aksylkük, aksylsary, saryyäshel, sarykyzyl* [2: 196-197] are also impossible to be considered as joined-up written words. We should be reminded that the words *kara kuchkyl, kara körän, kara kyzyl* in the research of A. Kh. Nuriyeva "The Orthographic Dictionary of the Tatar Language" are not written together [6: 48-49].

Compounds with the first component *yarym*, *ul'tra, mega, arkhi, üz, ber, küp* and others, were perhaps first written together as a result of calquing from the Russian language. But their components keep their own meaning and intonationally they are pronounced separately as well: *yarymräsmi* (the correct form – *yarym räsmi), yarymžimerek (yarym žimerek), üzbeldekle (üz beldekle), üzyöreshle (üz yöreshle), üzirekle (üz irekle), berara (ber ara), beryakly (ber yakly), küpsanly (küp sanly), küppochmakly (küp pochmakly), küpyellyk (küp yellyk), küpkyrly (küp kyrly)*, *küpsyydyryshly (küp sydyryshly*), etc.

In order to reduce confusion in orthography some principles relating to word formation which have been recently formed probably should be changed a little (there is a necessity and an opportunity). For instance, why were the word combinations *kara küz, ozyn ayak, sary chäch, ak yöz, ike yak, öch faza, un kön, küp bala,* having attached a particular affix and having become a compound adjective, first written together?! Previously this kind of thing did not take place and this was right.

For example, the words *ber yäsh'lek, ber tomly, ber öylelär, ber öleshlelär, üzäк özgech* in the work "Dictionary of the Tatar Language" published in 1977 [7: 148-150], the words *küp balaly, küp basuly, küp baskychly, küp ižekle, küp millätle, küp mägnäle, küp sanly, küp tomly, küp fazaly, küp telle* in the work "Dictionary of the Tatar Language" published in 1979 [8: 300-301], and other words are reasonably given as compound words being written separately.

To conclude the paper about the spelling of compounds, it should be noted that the problem of writing compound words is quite complicated and that nowadays in this field different views and attempts to explain the same thing in different ways have come into existence. And as a result we can still see much confusion in the use of the language and in the orthography. It is obvious that spelling rules should be clear and unified.

The conclusion is that linguists in dialogue with each other, with teachers of the Tatar language and literature and with journalists should solve the issues concerning the current state of the language, taking the new requirements into consideration.

**References**


1. Tatarskaya grammatika. T.I. Kazan': Tatar.kn.izd-vo, 1993. 584 s. (in Russian).
2. *Ganiyev F.A.* Khäzerge tatar ädäbi telendä cüzyasalyshy. Kazan: Mägarif, 2006. 271 b. (in Tatar).
3. Tatar grammatikasy. T.II. Morfologiya. Mäskäü-Kazan: Insan-Fiker, 2002. 448 b. (in Tatar).
4. *Tumasheva D.G.* Khäzerge tatar ädäbi tele morfologiyäse. Kazan universitety näshr., 1964. 299 b. (in Tatar).
5. *Khisamova F.M.* Tatar tele morfologiyäce. Kazan: Mägarif, 2006. 335 b. (in Tatar).
6. *Nuriyeva A.Kh.* Tatar teleneŋ orfografik süzlege. Kazan: Mägarif, 1996. 144 b. (in Tatar).
7. Tatar teleneŋ aŋlatmaly süzlege. Öch tomda. T.I. Kazan: Tatar. kit. näshr., 1977. 476 b. (in Tatar).
8. Tatar teleneŋ aŋlatmaly süzlege. Öch tomda. T.II. Kazan: Tatar. kit. näshr., 1979. 726 b. (in Tatar).


---

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КОНВЕРСИЯ ҺӘМ ОРФОГРАФИЯГӘ КАРАГАН КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘР


**Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан, Кремль ур., 18 нче йорт,
dilara-47@mail.ru.



Бу мәкаләдә соңгы елларда кайбер татар галимнәренең сүз төркемнәренең берсеннән икенчесенә күчүен, ягъни конверсия күренешен аңлатуларында телнең табигый үзенчәлекләре, хосусияте объектив чагылыш тапмау сәбәпле бер сүз төркеменең хаксыз рәвештә икенче сүз төркеменә кертеп каралуы хакында сүз бара. Автор өстәмә мәгънәләрендә сирәк кенә, билгеле бер контекстларда гына кулланылып, тулысынча икенче мөстәкыйль мәгънәгә ирешмәгән сүзләрне конверсия юлы белән ясалган яңа сүзләр итеп атау хакыйкатькә туры килеп бетми дигән караштa тора. Мәкаләдә шулай ук кайбер сүзләрне кирәксезгә кушып язу белән мавыгу күренешенең туган телебезне куллануда зур буталчыклык китереп чыгаруы бәян ителә.



**Төп төшенчәләр**: бер сүз төркеменең икенчесенә күчүе, конверсия, сүз ясалу, ясагыч кушымчалар, сүзләрнең кушылып яки аерым язылуы, кушма һәм тезмә сүзләр.


Галимнәрнең татар теле сүзләрен төркемләү белән шөгыльләнә башлауларына гасыр ярымнан күбрәк вакыт узган. Шулай да бу юнәлештә әлегә кадәр бөтен мәсьәләләрдә дә бердәм фикергә ирешелгәне юк. Хәер, фәнни карашлар бер төрле була алмый, һәм моңа исәп тотарга да ярамый, чөнки матди һәм рухи тормыштагы бер нәрсә дә үзгәрешсез тормый. Телләр кулланылышы өлкәсендә дә, тел күренешләрен өйрәнә торган фәндә дә шулай: татар теленең тарихына, аның бүгенге торышына, сан һәм сыйфат ягыннан үзгәрешенә караган кайбер күренешләрне аңлау һәм аңлатуда, тасвирлауда төрлечә караш, фикер төрлелеге һәм каршылыгы хөкем сөрә. Бу табигый хәл. Әмма тел галимнәренең бурычы – телдәге үзгәрешләрне күз уңында тотып, тел фәнендә теге яки бу мәсьәләгә төрле карашларны өйрәнеп, алардагы фикер төрлелегенең чамасыз артып китмәвен

кайгыртып, бик әһәмиятле, хәлиткеч мәсьәләләрдә бердәмлеккә, тел фәненең гомумән алганда дөрес юнәлештә баруына, тел күренешләрен объектив яктыртуына ирешү.

Бу мәкаләнең максаты – татар теле сүзләрен төркемләү, бер сүз төркеменең икенчесенә күчүе – конверсия күренеше – һәм кайбер сүзләрнең аерым яки кушылып язылуы мәсьәләләренә бер караш бәян итү.

Заманнар узып, галимнәрнең саны арткан, аларның фәнни хезмәтләре күбәйгән саен, тел фәне катлаулана, тел күренешләрен аңлату да четереклерәк була, даими хәрәкәттәге җанлы телне катгый кагыйдәләргә яраклаштыру, калыпларга салу күренеше көчәя бара.

Кайбер фәнни хезмәтләрдә бер сүз төркеме икенчесенә күчә, берсе икенчесенә әверелә дип инандыру, аерым язылып килгән сүзләрне кушып язарга тәкъдим итү һәм тагын башка төрле карашлар – әлеге фикергә дәлилләр.

Соңгы ике-өч дистә елда татар теле фәненең сүз ясалышы дигән тармагында сүз төркемнәренең берсеннән икенчесенә күчүе, ягъни берсенең икенчесенә әверелүе теориясе шактый нык урын алды. 1993 нче елда нәшер ителгән «Татар теле грамматикасы»нда һәм башка берничә хезмәттә телебездәге йөзләрчә исемнәрнең сыйфат сүз төркеменә күчүе, ягъни сыйфатлашуы, сыйфатларның исемгә күчүе, ягъни исемләшүе, шулай ук башка төркемнәргә караган күп сүзләрнең берсеннән икенчесенә күчүе тасвирлана [1]. Мәсәлән, әле исеме аталган китапта әйтелгәнчә, *чал, саңгырау, изге, кече, кызу, яңа, иске, кәкре, көтәчәк* кебек сүзләр исемнәргә, *ефәк, ситсы, алтын, көмеш, пыяла, агач, салам, йон, күбәләк, гармун, дус, арыслан, дала, тау* кебек исемнәр сыйфатларга әверелә, диелгән [1: 334-339, 393-404].

Гомумән, телдәге теге яки бу сүзнең икенче сүз төркеменә күчүе дигән төшенчә белән сак эш итү кирәк һәм мондый күренешне зурайтып, абсолютлаштырып күрсәтү һәр очракта да үзен аклап бетерми. Хәлбуки, шактый тел галимнәрендә мондый мавыгулар бар. Грамматикаларда һәр сүзне һәм әйтелмәне катгый рәвештә ниндидер бер кагыйдәгә яраклаштыруга һәм билгеле бер схемаларга урнаштырырга омтылу моның төп сәбәбе булып тора.

Мисал өчен, *көмеш алка, бакыр савыт, агач шкаф* кебек иярүче сүзе материалны белдерә торган исем сүзтезмәләрне алып карыйк. Болардагы һәм шуларга охшаш йөзләрчә, меңнәрчә сүзтезмәләрнең материалны белдерә торган беренче кисәкләре «Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы» дигән китапта исемнән сыйфатка күчкән сүзләр, икенче төрле әйткәндә, конверсия юлы белән ясалган сыйфатлар дип атала [2: 201-202].

Мондый карашның авторы, бу мисаллардагы *көмеш, бакыр, агач* сүзләрен, ихтимал, рус телендәге «относительные прилагательные» дип атала торган сүзләргә ияреп, сыйфат дип атагандыр (чагыштырыгыз: *көмеш* алка – *серебряные* серьги, *бакыр* савыт – *медная* посуда, *агач* шкаф – *деревянный* шкаф).

Шулай ук кайбер тел галимнәренең мондый сүзтезмәләрдәге материал исемнәрен белдергән сүзләрне сыйфат дип атауларының сәбәбе сыйфат сүз төркеменең грамматика китапларында урын алган билгеләмәсенә берьяклы гына караулары белән дә аңлатыла булса кирәк. «Предметның билгесен белдереп, *нинди? кайсы? кайдагы?* кебек сорауларга җавап бирә торган сүз төркеме сыйфат дип атала» дип әйтелә ул билгеләмәдә. Хәлбуки, бу билгеләмәдә бер әһәмиятле сүз төшеп калган: ул *даими* сүзе – «предметның даими билгесен белдереп» диелсә, сыйфатның асылы ныграк ачылыр иде.

Хикмәт анда гына да түгел: сүз төркемнәрен билгеләгәндә, *нинди?* соравына җавап бирә торган сүзләрне сыйфат дип атау гадәткә кергән. Бу, әлбәттә, чынбарлыкны тулы чагылдырмый: *нинди? кайсы?* сорауларына җавап биргән сүзләр һәр очракта да предметның билгесен белдерә дип әйтеп булмый. М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева, Ф.М.Хисамова һәм башка күренекле тел галимнәре сүз төркемнәрен билгеләгәндә сүзләрнең төрле билгеләрен һәм сөйләмдә башкарган вазифаларын исәпкә алырга кирәк, дип өйрәтәләр һәм бу фикерләрен ышандырырлык итеп дәлилилиләр [3: 13-15; 4: 22-31, 41-42; 5: 59-64]. Сүз төркемнәрен билгеләгәндә аларның аеруча киң таралган, күпчелек очракта кулланыла торган төп лексик мәгънәләре һәм сөйләмдәге типик вазифалары (синтаксик функцияләре) хәлиткеч роль уйный.

*Ефәк күлмәк, алтын сәгать, тимер көрәк* сүзтезмәләрендәге *ефәк, алтын, тимер* ***нинди?*** соравына җавап бирсәләр дә, күлмәкнең, сәгатьнең, көрәкнең билгесен (сыйфатын) түгел, материалын белдерәләр. Материал исә үзе дә предметны тәшкил итә. Аларны берсе – әйбернең үзен, икенчесе материалын белдергән ике кисәктән торган тезмә исем итеп карау дөресрәк булыр иде, бәлки. Мәсәлән: *ефәк*

*күлмәк* – үзе бер бөтен төшенчә, *алтын сәгать* – үзе бер, *тимер көрәк* – үзенә бер төшенчә. Бу тезмә исемнең сыйфат сүз төркеме белән тәгъбир ителгән билгесе булырга мөмкин: *нәфис ефәк күлмәк, матур алтын сәгать, уңайлы тимер көрәк*.

Татар телендәге шушы схема буенча төзелгән меңнәрчә сүзтезмәләр асылда үзенчәлекле тезмә исемнәрне тәшкил итәләр: *тимер юл, асфальт юл, агач йорт, күн куртка, йон кофта*. Без инде күптәннән бирле тезмә яки кушма сүз дип исәпләргә күнеккән *ташаяк (таш савыт), ир кеше, ир бала, кыз бала, студент егет, врач кыз* кебек тезмә сүзләрнең икенче компонентларына, беренчеләренә карап, формаль рәвештә *нинди?* соравы куеп булса да, алардагы *таш, ир, кыз, студент, врач* сүзләрен *аяк (савыт), кеше, бала, егет, кыз* исем сүз төркемнәренең билгеләрен белдерә торган сүзләр дип, һич кенә дә әйтеп булмый. Алар бөтен (ике кисәге дә бергә) килеш үзләренә билге белдерә торган сүзләр – сыйфатлар ияртә алалар: *матур ташаяк (таш савыт), тырыш ир кеше, акыллы ир бала, чибәр кыз бала, уңган студент егет, игелекле врач кыз*, *иске тимер шкаф.*

«Татар теле грамматикасы»ның I томында сыйфатларның исем сүз төркемнәренә күчүенә мисаллар итеп китерелгән күп санлы сүзләрнең кайберләрен күздән кичереп, бу хактагы фикерләребезне ирештерик [1: 334-339].

*Ак, кыю, сылу, изге, өлкән, караңгы, кызу, яңа, ватык* кебек исем сүз төркемнәренә күчә, ягъни исемләшә торган сыйфатлар, дип тәкъдим ителгән сүзләрне төп мөстәкыйль мәгънәләрендә предметларны белдерә торган сүзләр дип кабул итү мөмкин түгел. Мәсәлән, *ак* һәм *яңа* дип әйтүгә, беренче чиратта, күз алдына ак төс һәм яңа әйбер килә. *Ак килә* дигән җөмлә төзесәк, *ак*ны исем яки исемләшкән сүз дип аңлап булмый: анда предмет мәгънәсе юк. *Кеше (ир кеше) килә* дигән җөмләдә кешенең (ир кешенең) лексик мәгънәсе ачык аңлашыла, чөнки ул субъектны белдерә торган сүз һәм исем сүз төркеменә карый.

Аңлашыла ки, бер сүз төркеменең икенчесенә күчүе, ягъни конверсия ысулы белән сүз ясалуның нигезендә теге яки бу сүзнең сөйләмдә (контекстта) үзе ияреп килгән сүз төшеп калган очракта аның лексик мәгънәсен һәм грамматик күрсәткечләрен алуы ята: *укучы кызның китабы – укучының китабы; гөнаһсыз балаларның күз яше – гөнаһсызларның күз яше; мин күп нәрсәләр күрдем – мин күпне күрдем; икенче китап онытылып калган – икенчесе онытылып калган* һ.б.ш.

Кайбер телчеләр тарафыннан бер сүз төркеменнән икенчесенә күчә, дип йөртелә торган сүзләр (сүз төркемнәре) элекке мәгънәләрен югалту-югалтмау дәрәҗәсе, яңа мәгънәдә кулланылуы активлыгы ягыннан бер-берсеннән шактый нык аерылалар. Яңа мәгънәсендә сирәк кенә, билгеле бер контекстларда гына кулланыла торган, яңа мәгънәсендә ныгып җитмәгәннәрен, димәк, мөстәкыйль сүз дәрәҗәсенә ирешмәгәннәрен конверсия юлы белән яңа сүз ясалу дип билгеләү хакыйкатькә туры килми. Андыйларны яңа мәгънәдә контекстуаль, вакытлы һәм сирәк кулланылышлы, ягъни конкрет бер очракта гына икенче сүзнең вазифаларын башкара торган сүзләр дип атау дөресрәк булыр иде. Мәсәлән, «Укучылар кичә үткән материалны кабатладылар» – «Укучылар кичә үткәнне кабатладылар». Монда *үткән материал* сүзтезмәсендәге *материал* сүзе төшеп калу аркасында, *материал* сүзе белән белдерелгән исемнең предметлык мәгънәсен *үткән* сүзе үзенә ала һәм аның грамматик күрсәткечләрен кабул итә. Ләкин бу күренеш бары тик шушы контекстта гына булганлыктан, *үткән* сыйфат фигыленең икенче сүз төркеменә күчүе, ягъни конверсия юлы белән яңа сүз ясалу хакында җитди сүз алып бару мөмкин түгел.

Тулы конверсия, ягъни бер сүзнең икенче бер сүз төркеменә тулысынча күчүе, аның, элекке лексик-грамматик мәгънәсен җуеп, икенче сүз төркеменең лексик-грамматик мәгънәсен үзләштерүеннән һәм шул мәгънәдә киң кулланыла башлавыннан гыйбарәт. Моңа мисал итеп, сыйфат һәм исем фигыльләрдән исемгә күчкән (исемгә әверелгән, исемләшкән дисәң дә була) *яшьләр, кызыллар, аклар, күрше, укытучы, укучы, тегүче, язучы, буяу, язу, белдерү, сайлау* сүзләрен кертергә була.

Әмма тулысынча конверсияләнгән дип аталган мондый сүзләр дә элекке мәгънәләрен югалтып бетермиләр. Мисаллар: *Безгә язучылар* (исем) *килде. Президиумда беркетмә язучы* (сыйфат фигыль) *кеше утыра иде. Күршем* (исем) – *бик әйбәт кеше. Күрше* (сыйфат) *авылдан кунаклар килде. Халкыбыз зур җиңүгә* (исем) *иреште. Ярышта җиңү* (исем фигыль) – *һәркемнең теләге.*

Гомумән алганда, кайбер сүзләрнең формаль яктан бернинди дә үзгәрешсез икенче

сүз төркеменә күчүләрен яңа сүз ясалу дип шартлы рәвештә генә әйтергә мөмкин. Андый сүзләрне яңа, өстәмә мәгънә алган сүзләр дип атау муафыйк булыр иде, чөнки яңа сүз ясалганда, аның мәгънәсе белән бергә формасында да үзгәреш (яңалык) булырга тиеш. Сүзләр ясалуга, безнеңчә, гамәлдәге сүзләргә кушымчалар ялганып, яңа мәгънәле һәм үзгә формалы сүзләр төзелү, ягъни морфологик һәм фонетик юл белән сүз ясалу (*иген+че, ягу+лык, әңгәмә+дәш, каршы+ла, тырма+ла; сыпыру – себерү, күр – күз, багыр – бәгырь*) керә.

Сүзләр ясалу өлкәсендәге әлегәчә хәл ителмәгән мәсьәләләрнең берсе – *-лы/-ле, -сыз/-сез, -дагы/-дәге (-тагы/-тәге)* кушымчаларының исемнәргә ялганып, сыйфатлар ясаучы аффиксалармы яки исемнәрне исемгә бәйли торган кушымчалармы икәнлегенең ачыкланып бетмәгән булуы. Традиция буенча грамматика дәреслекләрендә аларны ясагыч кушымчалар итеп карыйлар. Шул ук вакытта М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева, Ф.М.Хисамова һәм тагын берничә галим аларның, нигездә, грамматик вазифа башкара торган аффикслар булуын таныйлар [3: 13-15; 4: 92-97; 5: 122-124].

Мәсәлән, бу кушымчалар ярдәмендә ясалып, сыйфатлар дип йөртелгән сүзләрнең асылда сыйфатлар түгеллеге ачык күренеп тора. *–лы/-ле* кушымчасының төп вазифасы – сүзнең тамырындагы предметның кемгәдер яки нәрсәгәдер караганлыгын белдерү: *атлы* (атка ия) *крестьян, балалы* (баласы булган) *хатын, пәрдәле* (пәрдәсе булган) *тәрәзә*. Хәер, кайбер очракларда бу кушымча бер предметның икенчесендә табылуын гына күрсәтми, бәлки аңа ниндидер уңай бәяләү төсмере дә өсти: *эчтәлекле* (эчтәлеге бай, яхшы мәгънәсендә) *әсәр, башлы* (акыллы, фикерле мәгънәсендә) *кеше*.

*-сыз/-сез* кушымчасының сөйләмдәге төп вазифасы – исемнәргә ялганып, тамырында аңлашылган предметның икенче предметта булмавын, юклыгын белдерү: *бакчасыз* (бакчасы булмаган) *йорт, кояшсыз* (кояш чыкмаган, болытлы) *көн*. Әмма бу кушымча да кайбер очракларда предметның билгесен дә белдерергә мөмкин: *денсез* («динсез»дән), *имансыз* (юньсез, әшәке) *кеше*.

Ике кисәктән торган *-дагы/-дәге//-тагы/-тәге* кушымчасының да төп роле – бер предметның икенче предметта урнашканлыгын белдерү: *урмандагы агачлар, кырдагы игеннәр*.

*-лы/–ле* аффиксын – барлык килеше, *-сыз/-сез* кушымчасын юклык килеше кушымчалары дип атау хакыйкатькә күбрәк туры килер иде.

Нисби сыйфат ясагыч дип йөртелә торган *-гы/-ге, -кы/-ке* аффиксы да, чынлыкта, исемнән предметның билгесен белдерә торган сыйфат ясамый. *Кышкы юл* сүзтезмәсендә «кышкы» *юл* сүзе белән тәгъбир ителгән предметның билгесен түгел, бәлки аның вакытка мөнәсәбәтен белдерә: *кышкы* (кыш көне була торган) *юл, җәйге* (җәй фасылындагы) *көн, кичке* (кич белән ашала торган) *аш, аскы* (астагы) *кат*. Бу кушымча яңа мәгънәле сүз ясый икән (телдә полифункциональ аффикслар күп), ул очракта аны сүз ясагыч кушымчалар исәбендә дә карарга мөмкин.

Мәсьәләгә җитдирәк якын килгәндә, бер сүз төркеменең икенчесенә күчүе кебек төшенчәләр логикага туры килеп тә бетми. Сүзләрне сүз төркемнәренә бүлгәндә, аларның, нигездә, күп мәгънәле икәнлеге онытып җибәрелә кебек. Телдәге шушы бик әһәмиятле күренешне – сүзләрнең күп мәгънәлелеге хосусиятен исебездә тотып эш ителсә, сүзләрнең (сүз төркемнәренең) берсенең икенчесенә күчүе, әверелүе төшенчәләреннән арынып, сөйләмдә сүзләр билгеле бер мәгънәсендә, тиешле грамматик күрсәткечләр алып, бер сүз төркеменә, икенче мәгънәсендә, башка төрле морфологик күрсәткечләргә ия булып, икенче бер сүз төркеменә карый, дип әйтсәк, бу – чынбырлыкны ныграк чагылдырыр иде. Шундый караш белән эш иткәндә, сүзләр берсеннән икенчесенә күчә дип тормыйча, мәсәлән, *салкын* сүзе һаваның билгесен белдергәндә (*салкын һава*) сыйфат сүз төркеменә карый, *январь салкыннары* сүзтезмәсендә исем ролендә килә дип кенә әйтәсе булыр иде. Нинди сүз кайсы сүз төркеменә карый дигән бәхәсләр дә булмас иде. Мәсәлән, *ишектән салкын* (исем) *керә. Салкын* (сыйфат) *кыш башланды*.

Сүзләр – лексик-грамматик яктан бер-берсеннән аерылып бетмәгән (дифференциацияләнмәгән) лексик берәмлекләр. Бу күренеш телнең барлыкка килү табигате белән бәйләнгән: кешеләр башта предметка исем тапканнар һәм шул исем белән предметның билгесен дә атаганнар, дип фараз ителә. Шулай булгач, андый сүзләрнең кайсысы кайсы сүз төркеменә күчкәнлеген ачыкларга омтылуның кирәге дә юктыр һәм бу эш мөмкин дә түгелдер. Аларның һәркайсы конкрет очракта мөстәкыйль рәвештә үз мәгънәсендә

кулланыла, дөресрәге, тел ияләре аларны теләгәнчә кулланалар. Һәм шунлыктан, «Хәзерге татар әдәби телендә сүзъясалышы» китабында язылганча [2: 228], *дөрес, азат, акрын, анык, алама, озын, начар, кире, яхшы, таза, тирән, авыр, җиңел, ерак* кебек сүзләргә «рәвешләргә генә күчә торган сыйфатлар» дигән мөһер сугарга кирәк түгелдер. Тел ул – җанлы, гаҗәеп катлаулы күренеш, аның сүзләре үзенчәлекле, күп төрле мәгънәле, бизәкле, һәм алар шактый үҗәт: китапларда сурәтләнгән кагыйдәләргә буйсынырга, әзер калыпларга күндәм генә кереп урнашырга ашкынып тормыйлар. Мәсәлән, рәвешләргә генә күчә торган дип билгеләнгән сыйфатлар арасындагы *авыр* сүзе телебездә *йөк, корсак, көмән* мәгънәләрендәге исем сүз төркеме буларак та кулланыла (*Авыры бар, күрәсең*).

Ихтимал, норматив тел дәреслекләре, татар теленнән ярдәмлекләр язып, бастырып чыгарганда, артык катлаулы, бәхәсле, тәгаен ачыкланып җитмәгән мәгълүматларны бәян итү белән мавыгу кирәкмәстер. Грамматика, андагы кагыйдәләр, билгеләмәләр һәм башка төрле теоретик материаллар телне гамәли яктан өйрәнүгә, укучыларны туган телләрендә дөрес, матур, аһәңле итеп сөйләргә, сөйләшергә өйрәтү өчен нигез, чара, ярдәмлек буларак хезмәт итәргә тиеш. Югыйсә, соңгы елларда уку йортларында тел дәресләрендә һәм дәреслекләрендә туган телне, җанлы аралашу коралы (коммуникатив чара) буларак өйрәтүгә караганда, күбрәк теоретик материал итеп өйрәтү өстенлек ала башлады.

Тел фәненең гамәли әһәмияте турындагы фикерне үстереп, тагын бер мөһим мәсьәлә хакында фикеребезне җиткерәсе килә. Бу – кайбер сүзләрнең кушылып яки аерым язылышы мәсьәләсе. Хикмәт шунда: матбугат материалларында, төрле китапларда һәм, гомумән, язма телебездә кушылып яки аерым язылышы тәгаен ачыкланмаган һәм шунлыктан төрлечә языла торган сүзләр шактый күп.

Гомумән алганда, сүзләрнең язылышы өлкәсендә буталчыклык, төрлечә эш итү күренеше бүгенге көн практикасында шактый зур урын алып тора. Бу – җитди, четерекле бер мәсьәлә. Тел галимнәренә, бергәләшеп, уртак фикергә килеп, аны тиз арада хәл итәсе, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре һәм яңа орфография сүзлекләре язып, бастырып чыгарасы бар.

Сүзләрнең дөрес язылышына караган төп проблема – тезмә сүзләр компонентларының аерым язылысы урында нигезсез кушылып язылуында. Соңгы вакытларда кушма, тезмә сүзләрне һәм сүзтезмәләрне язуда катгый кагыйдәләргә нигезләнеп эш итү җитми. Бу өлкәдә башбаштаклык хөкем сөрә.

Бүгенге көндә кушма һәм тезмә сүзләрнең мөстәкыйль мәгънәләре сакланган кисәкләрен кушып язу белән мавыгу гадәткә кереп бара. Мәсәлән, алда атап үтелгән «Хәзерге татар әдәби телендә сүзъясалышы» дигән хезмәттә моңарчы аерып язылган күп кенә тезмә сүзләр кушылып языла. Хәтта китапның исемендәге *сүзъясалышы*ның ни өчен кушылып язылганлыгы аңлашылмый. *Сүз ясалышы* ул тезмә сүз дә түгел, сүзтезмә бит! Бу китапта тәкъдим ителгәнчә, *күпмилләтле, күпбалалы, күпбуынлы, күпсүзле, сарычәчле, озынкуллы, өчфазалы, берьяклы, икеяклы, таңкалдыргыч, эчпошыргыч, бишьеллык, ункөнлек, бишкөнлек, өчатналык* [2: 199] кебек мөстәкыйль мәгънәләре ачык беленеп торган компонентлардан торган тезмә һәм кушма сүзләрнең кушылып язылуы өчен нигез күренми: алар аерым язылырга тиеш. *Паръясалу, җиртетрәү, башәйләнү, бермәгънәле, беркатлы, бермөгезле, каракүк, каракызыл, караяшел, күкселкара, чиякызыл, шомырткара, әфлисунсары*, *аксылкүк, аксылсары, сарыяшел, сарыкызыл* сүзләрен дә [2: 196-197] кушылып языла торган сүзләр итеп тану мөмкин түгел. Искәртеп китик: *кара кучкыл, кара көрән, кара кызыл* кебек сүзләр А.Х.Нуриеваның «Татар теленең орфографик сүзлеге»ндә кушылып язылмаган [6: 48-49].

Беренче компонентлары *ярым*, *ультра, мега, архи, үз, бер, күп* һәм башка сүзләрдән торган кушма һәм тезмә сүзләр, рус теле сүзләрен калькалаштыру нәтиҗәсендә кушылып языла башлаган булса кирәк. Хәлбуки, аларның компонентлары мөстәкыйль мәгънәләрен тулысынча саклыйлар һәм интонацион яктан да аерым әйтеләләр: *ярымрәсми* (дөресе – *ярым рәсми), ярымҗимерек (ярым җимерек), үзбелдекле (үз белдекле), үзйөрешле (үз йөрешле), үзирекле (үз ирекле), берара (бер ара), берьяклы (бер яклы), күпсанлы (күп санлы), күппочмаклы (күп почмаклы), күпьеллык (күп еллык), күпкырлы (күп кырлы)*, *күпсыйдырышлы (күп сыйдырышлы*) һ.б.

Орфографиядәге төрлелекне, дөресрәге, буталчыклыкны киметү өчен, сүз ясалышына карата соңгы елларда урнашкан кайбер принципларны яңадан бер кат уйлап, кирәк дип табылса

(мондый ихтыяҗ һәм мөмкинлек бар), ихтимал, кайберләрен берникадәр үзгәртергә кирәктер. Мәсәлән, ни өчен *кара күз, озын аяк, сары чәч, ак йөз, ике як, өч фаза, ун көн, күп бала* кебек сүзтезмәләр, икенче компонентларына тиешле кушымчалар ялганып, тезмә сыйфатларга әверелгәч, кушылып языла башлый?! Элек андый хәл юк иде, һәм бу дөрес тә булгандыр. Мәсәлән, 1977 елда чыгарылган «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *бер яшьлек, бер томлы, бер өйләләр, бер өлешләләр, үзәк өзгеч* [7: 148-150], 1979 елда чыгарылган «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә *күп балалы, күп басулы, күп баскычлы, күп иҗекле, күп милләтле, күп мәгънәле, күп санлы, күп томлы, күп фазалы, күп телле* [8: 300-301] һ.б.ш. сүзләр хаклы рәвештә аерым языла торган тезмә сүзләр буларак бирелгән.

Кушма һәм тезмә сүзләрнең язылышына караган фикерне йомгаклап, шуны әйтик: кушма һәм тезмә сүзләрнең язылышы проблемасы шактый катлаулы һәм четерекле, һәм бу өлкәдә бүгенге көндә төрлелек, бер үк күренешне төрле карашка нигезләнеп тасвирлау хөкем сөрә. Нәтиҗәдә телне куллануда, сүзләрне дөрес язу мәсьәләсендә башбаштаклык хөкем сөрә. Аңлашыла ки, язу кагыйдәләре катгый, бер төрле булырга тиеш.

Нәтиҗә: тел галимнәренә, үзара һәм тел-әдәбият укытучылары, журналистлар белән фикер алышып, телебезнең бүгенге халәтенә, сыйфатына кагылышлы проблемаларны яңа таләпләрне исәпкә алып хәл итәргә кирәк.

**Әдәбият**


1. Татарская грамматика. Т.I. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993, 584 с.
2. *Ганиев Ф.Ә.* Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. Казан: Мәгариф, 2006. 271 б.
3. Татар грамматикасы. Т.II. Морфология. Мәскәү-Казан: Инсан-Фикер, 2002. 448 б.
4. *Тумашева Д.Г.* Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан ун-ты нәшр., 1964. 299 б.
5. *Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе. Казан: Мәгариф, 2006. 335 б.
6. *Нуриева А.Х.* Татар теленең орфографик сүзлеге. Казан: Мәгариф, 1996. 144 б.
7. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т.I. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 476 б.
8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т.II. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.


---

# КОНВЕРСИЯ ЧАСТЕЙ РЕЧИ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ И НЕКОТОРЫЕ ВОПРОСЫ ОРФОГРАФИИ


**Рузаль Абдуллазянович Юсупов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, ул.Кремлевская, д. 18,
dilara-47@mail.ru.



Статья посвящена осмыслению специфики механизма конверсии в татарском языке. Автор стремится доказать несостоятельность утвердившейся в современном татарском языкознании точки зрения, согласно которой любое контекстуальное значение слова считается основанием для определения данного явления как переход слова из одной части речи в другую. На основе анализа языкового материала делается вывод о необходимости при рассмотрении случаев конверсии учитывать многозначность лексических единиц. Размышляя о правописании отдельных слов, автор выражает озабоченность тем, что в последнее время в языковой практике наблюдается необоснованное увлечение слитным написанием, хотя отдельные их компоненты полностью сохраняют самостоятельное значение.



**Ключевые слова**: переход слов из одной части речи в другую, конверсия, словообразование, аффиксы, слитное или раздельное написание слов, сложные слова и словосочетания.